ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станции
Высокая Гора, Высокогорский район,
Республика Татарстан, 422700

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

Кооперативная ур, 5. Биектау т/ю
станциясе поселогы, Биектау районы,
Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-61, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
29.06.2024

**К А Р А Р**
№ 608

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының «Биектау муниципаль районында гражданнар оборонасын оештыру һәм алып бару турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2023 елның 4 августындагы 1047 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Муниципаль норматив-хокукый актларны хокукый мониторинг нәтиҗәләре буенча гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының «Биектау муниципаль районында гражданнар оборонасын оештыру һәм алып бару турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2023 елның 4 августындагы 1047 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районында гражданнар оборонасын оештыру һәм алып бару турындагы нигезләмәнең 15.2 пунктындагы 2 абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«халыкка хәбәр итү системаларын, шул исәптән халыкка хәбәр итүнең муниципаль һәм локаль системаларын булдыру, реконструкцияләү һәм куллануга даими әзерлек хәлендә карап тоту».

2. Әлеге карарны Интернет челтәрендә Биектау муниципаль районының рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ веб-адрес буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында: http://pravo.tatarstan.ru урнаштырып бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

Җитәкче Д.Ф. Шәйдуллин